КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 февраль г.Казань № 58

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2013 ел, 22 август, 591 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2013 ел, 22 август, 591 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «төзү» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

преамбулада «төзү» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

1 пунктта «төзү» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы" сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасы исемендә «төзү» сүзен «төзү» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин